**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**21 нче ноябрь 2023 ел** **№ 357**

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын раслау» Биектау муниципаль районы Советы карары проекты турында 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 статьясына, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы законына, Биектау муниципаль районы Уставына, Биектау муниципаль районында гавами тыңлаулар турында Нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын раслау» проектын нигез итеп кабул итәргә һәм гавами тыңлауларга чыгарырга. (1 нче кушымта)

2. Расларга:

2.1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставын раслау» Биектау муниципаль районы Советы карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен (2 нче кушымта);

2.2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү турында» Биектау муниципаль районы Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибен (3 нче кушымта).

3. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставын раслау» Биектау муниципаль районы Советы карары проекты буенча керүче тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эш төркеме төзергә:

1) Шакиров Ә.Ш. – Биектау муниципаль районы Башлыгы урынбасары;

2) Сабирова А.И. – Биектау муниципаль районы Советының юридик бүлеге начальнигы;

3) Мөстәкыймова Э.Ф. – Биектау муниципаль районы Советының оештыру бүлеге начальнигы.

4. 2023 елның 18 декаберендә 9.00 сәг. 422700, Биектау т/юл ст. пос., Кооперативная ур., 5 й. адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы бинасындагы утырышлар залында Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставын раслау» карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

5. Эш төркеменә Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставын раслау» карары проектына төзәтмәләр һәм тәкъдимнәрне өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы каравына кертергә.

6. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисаметдинов